ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Большая Красная, 15/9, г. Казань,420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ

Большая Красная ур., 15/9, Казан ш., 420111

тел/факс. 8 (843) 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 235

ПРИКАЗ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　　БОЕРЫК

12 август, 2016 ел

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең
17.12.2014 № 200 боерыгы белән расланган
Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан
күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек
эшчәнлеген башкаруга карата лицензия бирү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
үзгәрешләр кертү хакында

2014 елның 1 декабрендәге “Инвалидларның хокуклары турында конвенцияне ратификацияләүгә бәйле рәвештә инвалидларны социаль яклау мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” № 419-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 25 декабрендәге “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында” № 1434 карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” № 880 карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 17.12.2014 № 200 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген башкаруга карата лицензия бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектәге 1.3 пунктны яңа эчтәлегендә бәян итәргә:

“1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе (алга таба – ТР ДТИ) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. ТР ДТИ урнашкан урын: Казан ш., З.Кызыл ур., 15/9 й.

ТР ДТИ эш графигы: көн саен, шимбә һәм якшәмбедән кала, дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 9.00 сәгатьтән башлап 18.00 сәгатькә кадәр, җомга: 9.00 сәгатьтән

16.45 сәгатькә кадәр, төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Җәмәгать транспортында "Ирек мәйданы" тукталышына кадәр килергә кирәк:

- автобуслар: N 10а, 22, 28, 28а, 30, 35, 52, 54, 63, 89, 91, 98;
- троллейбуслар: N 2, 3, 5, 7, 8;
- метро (иң якын станция – "Кремль урамы").

Керү кертү кәгазе һәм (яки) шәхесне таныклый торган документ белән.

1.3.2. Лицензияләүче бүлекнең белешмә телефоннары (алга таба – бүлек): (843) 236-94-45.

1.3.3. "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендә (алга таба – "Интернет" челтәре) ТР ДТИ рәсми сайты адресы: https://gji.tatar.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турындагы мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) ТР ДТИ бинасында урнашкан, дәүләт хезмәте турындагы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмати стендлар аша.

Мәгълүмати стендларда урнаштырыла торган мәгълүмат шушы Регламентның 1.1., 1.3.1., 2.3., 2.4., 2.5., 2.8., 2.10., 2.11., 5.1. пунктларында (пунктчаларында) булган дәүләт хезмәте турындагы белешмәләрне үз эченә ала;

2) "Интернет" челтәре аша:

ТР ДТИ рәсми сайтында (https://gji.tatar.ru);

Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatar.ru/);

Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) ТР ДТИ телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яки телефон аша);

4) ТР ДТИ язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.".;

1 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 1.4 пунктны өстәргә:

"1.4. Дәүләт хезмәте түбәндәгеләргә нигезләнеп күрсәтелә:

Россия Федерациясе Торак кодексы (алга таба – РФ Торак кодексы) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2005, № 1, ст. 14, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Салым кодексы (икенче кисәге) (алга таба – РФ Салым кодексы) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2000, № 32, ст. 3340, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2008 елның 26 декабрендәге "Дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольлекне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында" № 294-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2008, № 52 (1 өл.), 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2009 елның 9 февралендәге "Дәүләт органнарының һәм җирле үзидарә органнарының эшчәнлеге турындагы мәгълүматтан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү хакында" № 8-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2009, № 7, 776 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2010 елның 27 июлендәге "Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль

закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2011 елның 4 маендагы “Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләү турында” № 99-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 99-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2011, № 19, 2716 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

2014 елның 21 июлендәге “Россия Федерациясе Торак кодексына, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләрен көчен югалткан дип тану турында” № 255-ФЗ Федераль (алга таба – № 255-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2014, № 30 (1 өл.), 4256 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Президентының 2012 елның 7 маендагы “Дәүләт идарәлеге системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында” № 601 Указы (алга таба – РФ Президентының № 601 Указы) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 6 октябрендәге “Лицензиянең үрнәк рәвешен раслау турында” № 826 карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 2011 елның 6 октябрендәге № 826 карары) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2011, № 42, 5924 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 21 ноябрендәге “Аерым эшчәнлек төрләрен лицензияләүне оештыру турында” № 957 карары (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2011, № 48, 6931 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 24 ноябрендәге “Россия Федерациясе Хөкүмәте һәм федераль башкарма хакимият органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында” № 953 карары (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2009, № 48, 5832 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 16 августындагы “Федераль башкарма хакимият органнарының һәм аларның вазифаи затларының, федераль дәүләт хезмәткәрләренең, Россия Федерациясенең дәүләти бюджетныкы булмаган фондлары вазифаи затларының, шулай ук атом энергиясе буенча “Росатом” дәүләт корпорациясенең һәм аның вазифаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр бирү һәм карап тикшерү тәртибе хакында” № 840 карары (“Федераль башкарма хакимият органнарының һәм аларның вазифаи затларының, федераль дәүләт хезмәткәрләренең, Россия Федерациясенең дәүләти бюджетныкы булмаган фондлары вазифаи затларының, шулай ук атом энергиясе буенча “Росатом” дәүләт корпорациясенең һәм аның вазифаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр бирү һәм карап тикшерү тәртибе” белән бергә) (Россия Федерациясенең законнар җыентыгы, 2012, № 35, 4829 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 28 октябрендәге “Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияләү турында” №1110 карары (алга таба – № 1110 карар) (Россия Федерациясенең законнар

җыентыгы, 2014, № 44, 6074 ст.);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2014 елның 28 октябрендәге “Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияләүгә карата дәүләт хезмәтен күрсәтү буенча административ регламентны эшләү буенча методик күрсәтмәләр, Россия Федерациясе субъектының дәүләт торак күзәтчелеге органы тарафыннан лицензия контрольлеген гамәлгә ашыруның административ регламентын эшләү буенча методик киңәшләр, күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияләгәндә кулланыла торган документларның рәвешләрен раслау турында” № 657/пр боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш министрлыгының 2014 елның 28 октябрендәге № 657/пр боерыгы);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтелүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” № 880 карары (алга таба – № 880 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 08.12.2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 26.12.2011 № 1068 карары белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм әмернамәләре һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы, 07.02.2012. № 10, 0383 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1 бүлекнең 1.5 пунктын түбәндәге төзәтмәсендә бәян итәргә:

“1.5. Бу Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

техник хата – дәүләт хезмәтен күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка кертелгән белешмәләрнең (дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсе) документка шуларга нигезләнеп кертелгән белешмәләргә туры килмәвенә китергән хата (хәреф, язу хатасы, грамматик яки арифметик хата);

дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкнең читтән торып эшләү урыны – муниципаль районнарның авыл җирлекләрендә мөрәҗәгать итүчеләрнең документларын кабул итү һәм аларга тапшыру, консультацияләү тәрәзәсе.

Бу Регламентта дәүләт хезмәтен күрсәтү турындагы гариза дигәндә (алга таба – гариза) дәүләт хезмәте күрсәтелү турында гарызнамә аңлашыла (27.07.2010 №210-ФЗ Федераль законның 2 ст. 2 п.). Гариза стандарт кәгазьдә тутырыла (2 кушымта).”;

2 бүлектәге таблицаның 1 графасы аталышын түбәндәге төзәтмәсендә бәян итәргә: “Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы”;

2 бүлектәге таблицаның 2 графасы аталышын түбәндәге төзәтмәсендә бәян итәргә: “Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге”;

2 бүлектәге таблицаның 2.3 пунктын “Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге” графасында түбәндәгечә бәян итәргә:
“а) лицензия бирү (бирүдән баш тарту);
б) лицензияне яңадан рәсмиләштерү (яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту);
в) лицензия алырга теләүче, лицензиат турындагы белешмәләрне лицензияләр реестрына кертү;
г) лицензия дубликаты бирү;
д) лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә билгеле бер лицензия турында белешмәләр, кабул ителгән карар турында ТР ДТИ акты күчермәсе яисә сорала торган белешмәләрнең юклыгы турында белешмәләр бирү;
е) лицензиянең гамәлдә булуын туктату яки лицензияне гамәлдән чыгару турында карар”;

2 бүлектәге таблицада 2.4 пунктка түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

“Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең стандартына карата таләпнең аталышы” графасында “дәүләт хезмәте” сүзләреннән соң “шул исәптән, дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында туктату мөмкинлеге каралган очракларда, дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору чоры” сүзләрен өстәргә”;

“Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге” графасында түбәндәге эчтәлекле кызыл юлны өстәргә:

“з) дәүләт хезмәтен күрсәтү чорын туктатып тору каралмаган”;

2 бүлектәге таблицаның 2.5 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

“Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең стандартына карата таләпнең аталышы” графасында “мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиешле” сүзләреннән соң “, мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе”;

“Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге” графасында беренче кызыл юлны түбәндәге эчтәлегендә бәян итәргә:

“Лицензия алу өчен түбәндәге документлар (белешмәләр) тапшырыла:

а) № 99-ФЗ Федераль законның 13 ст. 1 өлешендә каралган белешмәләрне күрсәтеп, лицензия бирелү турында гариза;

б) юридик затның нотариаль тәртиптә таныкланган гамәлгә кую документлары күчермәләре (юридик затлар өчен);

в) лицензия алырга теләүченең вазифаи затының квалификация аттестаты күчермәсе;

г) лицензия алырга теләүченең вазифаи затын вазифага билгеләү турындагы боерык күчермәсе;

д) теркәлүче документларның исемлеге”;

таблицадагы “Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге” графасында түбәндәге эчтәлекле 9, 10 пунктларын өстәргә:

“9. Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза кәгазен мөрәҗәгать итүче ТР ДТИ шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Әлеге кәгазьнең электрон рәвеше ТР ДТИ рәсми сайтында урнаштырылган.

10. Гариза белән аңа теркәлүче документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән (ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);

кулга тапшыру турындагы белдерүнамә белән почта аша заказлы хат итеп.

Гариза белән аңа теркәлүче документлар мөрәҗәгать итүче (шәхси эшмәкәр) тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гомуми файдаланудагы мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре, шул исәптән “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре һәм Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин”;

2 бүлектәге таблицаның 2.6 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

“Муниципаль хезмәтне күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы” графасында “тапшырырга хокуклы” сүзләреннән соң “, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны шушы документлар алар карамагында булган дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә оешмага тапшыру тәртибе”;

“Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге” графасында түбәндәге эчтәлекле сигезенче, тугызынчы кызыл юлларны өстәргә:

“Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм аларны тапшыру тәртибе шушы Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

Мөрәҗәгать итүчедән югарыда саналган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмаларның карамагында булган документларны таләп итү тыела”;

“Дәүләт хезмәтен күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы” графасындагы 2.13 пунктта “дәүләт хезмәте” сүзләреннән соң “, шул исәптән электрон рәвештә” сүзләрен өстәргә;

2 бүлектәге 2.14., 2.15. пунктларны түбәндәге төзәтмәләрендә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урыннарына карата, шул исәптән аталган объектларның Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнарына туры китереп, инвалидлар өчен файдалана алу мөмкинлеге белән тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы | Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар белән җиһазланган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә. Дәүләт хезмәтен күрсәтү урынына инвалидларның каршылыксыз үтеп керә алу мөмкинлеге тәэмин ителә (биналарга җайлы итеп керү-чыгу һәм аның чикләрендә хәрәкәт итү). Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән | |

| | | |
|---|---|---|
| һәм мультимедияле мәгълүматны урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең үтемлелек һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазифаи затлар белән хезмәттәшлек итү саны һәм аларның дәвамлылыгы, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә, шул исәптән дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урынында алу мөмкинлеге, дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмати-коммуникация технологияләреннән файдаланып | Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең үтемлелек күрсәткечләре:<br>ТР ДТИ бинасының җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>Мөрәҗәгать итүчеләрдән документларны кабул итүче белгечләрнең, бу гамәлләр башкарыла торган биналарның тиешле санда булуы;<br>ТР ДТИ мәгълүмати стендларында, “Интернет” челтәрендәге мәгълүмати ресурсларында, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталында дәүләт хезмәтен күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм вакытлары турында тулы мәгълүмат булу.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән сыйфатлана:<br>мөрәҗәгать итүчеләрдән документларны кабул иткәндә һәм аларга тапшырганда чиратлар;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтү чорларын бозулар;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтүче дәүләт хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата шикаятьләр;<br>дәүләт хезмәтен күрсәтүче дәүләт хезмәткәрләренең мөрәҗәгать итүчеләргә карата тотнаксыз, игътибарсыз мөнәсәбәтенә карата шикаятьләр.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелү турында гарызнамә тапшырганда һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алганда, дәүләт хезмәтен күрсәтүче вазифаи зат белән мөрәҗәгать итүченең бер мәртәбә хезмәттәшлек итүе күздә тотыла. Хезмәттәшлек итүнең дәвамлылыгы Регламентта билгеләнә.<br>Дәүләт хезмәте дәүләти һәм муниципаль хезмәтләрне күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба – КФҮ), КФҮ читтән торып эшләү урынында күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү барышы | |

| | | |
|---|---|---|
| | турындагы мәгълүмат мөрәҗәгать итүче тарафыннан ТР ДТИ сайтында http://www.gji.tatarstan.ru, Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында алынырга мөмкин. | |

3 бүлек аталышын түбәндәге төзәтмәсендә бәян итәргә:

“3. Административ гамәлләрнең составы, аларны үтәү эзлеклелеге һәм вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ гамәлләрне электрон рәвештә үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ гамәлләрне дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләренең читтән торып эшләү урыннарында үтәү үзенчәлекләре”;

3 бүлектәге 3.3 пунктының 3.3.2., 3.3.4., 3.3.5., 3.3.6. пунктчаларында, 7 кушымтада “урынга чыгып” сүзләрен “документар” сүзе белән алмаштырырга;

3 бүлекнең 3.9 пунктында “һәм муниципаль хезмәтләр” сүзләреннән соң “, КФҮ читтән торып эшләү урыннарында” сүзләрен өстәргә;

5 бүлектә 5.3 пунктта “почта,” сүзеннән соң “дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре аша” сүзләрен өстәргә.

2. Хокукый идарә бүлегенә (А.В. Абрамова) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Җыелма анализ һәм автоматлаштыру бүлегенә (И.С. Начвин) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәлгәннән соң Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык С.А. Крайнов